
ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ
В РЕСПУБЛИКЕ
ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Тукай ялкыны

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры **Апрель, 2024 нче ел** №7






**Балачак**

Бөек шагыйрь Арча ягының Кушлавыч авылында 1886 елның 26 апрелендә (иске стиль буенча 14 апрельдә) Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Малай туып дүрт ай ярым үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Бибимәмдүдәне (Габдулланың әнисен) Сасна Пучинкәсе авылы мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Соңрак аны үз әнисе яңа гаиләсенә алдыра. Бер елдан соң, 1890 елның 18 нче гыйнварында, әнисе үлеп китә, һәм Габдулланы бабасы Өчилегә алып китә. Ләкин бабасы алга таба Габдулланы асрау авыр булачагын аңлап баланы Казанга баручы бер ямщиккә утыртып билгесез сәфәргә озата. Печән базарына килгәч, халык арасыннан чыгып Мөхәммәтвәли абзый малайны үзләренә алып кайта. Әмма алар соңрак хатыны белән икесе дә авырып китәләр һәм Габдулланы яңадан Өчилегә озаталар. Бераздан соң малайны Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди абзыйга уллыкка озаталар. 2 елдан соң Кушлавыч авылының Бәдретдин исемле кешесе Тукайны эзләп таба да Уральскига алып китә.

**Уральск чоры**

1895 елның кышында 18 көнле юлдан соң тугыз яшьлек Апушны Уральскидагы татар бистәсенә сәүдәгәр Усманов Галиәскәр һәм аның хатыны Газизә йортына алып киләләр.1905—1907 елларда Тукай бик кыю публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый.Җизнәсе Галиәскәр вафат булганнан соң, Тукай Җаекның Кызыл мәчете каршындагы «Мотыйгия» мәдрәсәсенә күчеп килә.«Мотыйгыя» мәдрәсәсе каршында рус мәктәбе эшләп килгән. Алдан Тукай рус телен үзләштергән. Монда Тукайның рус һәм чит ил әдәбиятына мәхәббәте уяна. Иҗат юлының башында ул — укытучысы Мотыйгулла Төхфәтуллинның улына — Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укучы Камил Төхфәтуллинга бурычлы. 1905 елдагы революцион күтәрелү чоры Камилгә «Фикер» гәҗите, «Уклар» һәм «Новый век» журналын бастырырга мөмкинлек тудыра. Тукай бу басмаларда үзенең шигырьләрен киң җәмәгатьчелеккә чыгара.Тукай өчъеллык рус мәктәбенә кереп укый башлый. Мәдрәсәдә гарәп, төрек, фарсы телләрен бик яхшы үзләштергән малай рус һәм Европа әдәбияты дөньясына чума.1905 елның сентябрендә үк аның «Әлгасрелҗәдид» журналының реклама җыентыгында шигырьләре басыла. Ноябрьдә «Фикер» гәҗите чыга башлый. 1906 елның июнендә «Уклар» сатирик журнал дөнья күрә, Тукай анда фактик редактор булып эшли.


**Казан чоры**


1907 елның Тукай Казанга килә. Анда Тукай яңа дуслар таба: Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Кәбир Бәкер, В.Бәхтияров, Галиәсгар Камал, Солтан Рахманколый, Гафур Коләхмәтов, Сәгыйть Сүнчәләй. Габдулла үзе теләгән әдәбият, журналистика өлкәсенә чума. 1910 елның башында журналист Әхмәт Урманчиев редакторлыгында сатирик журнал «Ялт-йолт» чыга башлый, анда Тукайның сатирик әсәрләренең бик күбесе басыла. Тукай «Шәрык клубы» программасындагы кичәләрдә концертлар, лекцияләрне оештыруда Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, Ф. Агеев, С. Рахманколый белән бергә эшли. 1910 елның 15 апрелендә Шәрык клубында халык иҗаты буенча лекция укый. 1913 елның башында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый. Ләкин ул иҗат эшен туктатмый.1913 елның 15 апрелендә (иске стиль буенча 2 апреле) бөек шагыйрь Габдулла Тукайның гомере өзелә.











**Мәктәп яңалыклары...**

Тукай атналыгы кысаларында мәктәбебезгә Дәүләтова Рәмилә Идрис кызы очрашуга килде. Ул Габдулла Тукайның балалар өчен иҗат иткән шигырьләр китаплары белән таныштырды. Китап укуның әһәмияте турында укучыларга аңлатты.Г.Тукайның күп кенә шигырьләренә җырлар язылган.Укучыларга сораулар бирде.



"Асылташ" балалар театры Г.Тукайның "Кәҗә белән Сарык " әкиятен 1-6 нчы сыйныф укучыларына сәхнәләштереп куйдылар



8 һәм 9 сыйныф укучылары Светлякова Айгөл, Нуретдинова Зарина, Зәйдуллин Самат конференциядә "Топонимика. Туган як экологиясе" дигән темага чыгыш ясап 3 дәрәҗә дипломга лаек булдылар.



"Психология атналыгы" һәм "Киләчәккә Билет" һөнәри юнәлеш бирү проекты кысаларында педагог психолог Л.М. Хәлиуллина һәм сыйныф җитәкчеләре 6-11 сыйныф укучылары белән һөнәри юнәлеш бирү тәрбия сәгатьләре үткәрделәр. Укучылар биомедицина инженеры һөнәре белән таныштылар

# «Мәңге яши Тукай безнең күңелләрдә»

(Габдулла Тукайга багышланган әдәби – музыкаль кичә)

Талгын гына көй агыла.

Экранда Г.Тукайның сүзләре:

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт...

1 а.б. Хөрмәтле кунаклар, укытучылар һәм укучылар! Безнең бүгенге кичәбез татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышлана.

Экранда Г.Тукай турында замандашлары. Габит Мөсрепов, казах язучысы:-Без, казах язучылары, Г.Тукайны, Абай кебек үк, үзебезнең гомуми элгәребез дип саныйбыз. Тукай безне бөек рус әдәбиятына, алдынгы урыс культурасына якынайтучы булды.

2 а.б.Тукай музыкант та булмаган, көйләр дә язмаган, шулай да аның һәр шигыреннән моң бөркелә. Бөек шәхес турында күбрәк белгән саен ул, ничектер күңелгә һаман да якыная, аның иҗаты яңа яктан ачыла бара.(Талгын гкына көй агыла)"Җир йокысы" җыры

1 а.б.Безнең өчен гаять кадерле әсәрләр иҗат иткән шагыйрь гомере бик михнәттә һәм газапта яшәгән. Иске тормыш шартларында язмыш аны аяусыз кыерсыткан, каккан- суккан...

2 а.б. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай 1886 елның 26 апрелендә хәзерге Татарстанның Арча районына керә торган Кушлавыч авылында туа. Озак та үтми, аның әтисе үлеп китә. Ул чакта Габдулла биш айлык бала була.

(Башына кәләпүш, өстенә камзул, аягына читек кигән бер укучы кечкенә Габдулла кыяфәтендә тамашачылар алдына чыгып баса һәм сөйли башлый, акрын гына көй агыла):

- Авылда башка туганнарым булмаганлыктан, әни мине, вакытлыча Шәрифә исемле ярлы карчыкта калдырып, Сасна авылына кияүгә киткән. Шәрифә карчык исә мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән. Хәтта ачык йөз дә күрсәтмәгән...

2 а.б.Бераздан Габдуллны әнисе үзе янына Сасна авылына алдыра. Озакламый әнисе үлеп китә. Шуннан соң Габдулла кулдан – кулга йөри башлый. Шагыйрьнең балачагы Арча районы Кырлай авылында үтә. Хәзер анда музей – комплекс эшли.Шәкертләр биюе

2 а.б. Әйе, ятим бала якты йолдыз булып балкыды. Сүнмәс йолдыз булып калыкты. Сөекле шагыйребезнең шигырьләрен бабаларыбыз ятлаган, әти - әниләребез укып үскән, хәзер без аларны өйрәнәбез. Алар җанны җылыта, күңелне яктырта, туган телгә мәхәббәт тәрбияли.

Экранда Тукай турында замандашлары. Казах язучысы Сабит Мүканов, казах язучысы:-Безнең язучыларыбыз иҗатларында бөек Тукайдан үрнәк алганнар. Революциягә кадәр Россиядә Көнчыгыш милләтләре язучыларының берсе дә башка милләтнең әдәбиятына Тукай кебек тәэсир итә алмады, Тукай кебек хөрмәт казанмады.Укучылары башкаруында Г.Тукайның "Туган җиремә", "Китмибез", "Шагыйрьгә", "Милли моңнар", "Җәйге таң хатирәсе", "Өзелгән өмид", Дусларга бер сүз", "И каләм!", "Бәхетле бала" шигырьләрен сөйләү. ( "Тәфтиләү" җыры яңгырый"

2 а.б. Татар халык шагыйре Шәүкәт Галиев тә радиодан "Туган тел" җырын беренче тапкыр И.Шакиров башкаруында ишетеп уйга кала һәм мондый шигъри юллар яза:

Ишеттем мин читтә "Туган телне"<br>
Халкым: нинди моңлы көең бар?<br>
Тукаемны йотылып тыңлаганда<br>
Тамагымда кайнар төер бар.<br>
Кем ничектер, әмма мин бу җырны<br>
Тыңлыйм, тыңлап туялмыйм.<br>
Әсәрләрем сабый бала кебек<br>
Ир булсам да яшем тыялмыйм.

1 а.б. Бу көй җыр гына булып калмады: чын мәгънәсендә татар халкының гимнына әйләнде.Экранда Тукай турында замандашлары. Семен Липкин, тәрҗемәче, Г.Тукай бүләге лауреаты:-Ташкентта Азия һәм Африка илләре язучылары конференциясендә мин фарсы һәм төрки телләрен белә торган бер Ирак язучысы белән танышкан идем. Бу кеше болай диде:

-Минем Россиядә, Идел буенда бер дә булганым юк. Ләкин Габдулла ибне Мөхәммәт Гариф Тукайның "Шүрәле" исемле әсәрен укыгач, мин Россия урманнарының хуш исен тойдым.

Россия урманындагы айлы кич күз алдыма килә дә баса.

***-Сталинабадта искиткеч матур җәй иде. Соңгы көннәрем кичерә торган Садретдин Айнине креслосында бакча буйлап йөртәләр. Ул, кибеп, балалар кулыдай калган кулы белән иҗекләр санагандай итеп Бәдил шигырьләрен укый иде.

-Дамелла, иске Бохарада революциягә тикле Сезнең Пушкин турында ишеткәнегез булдымы?-дип сорадым.

-Әйе, ишеттем дә. Укыдым да, -диде дамелла.-Тукайдан укыдым.

Гафур голәм, Али Токымбаев, Мирза Турсын –задә һәм Урта Азиянең башка күп күренекле шагыйрьләре Тукайны балачактан ук белүләрен, яратып укуларын әйтәләр.

(Җыр көчәеп дәвам итеслә)

2 а.б. Тукайның шигырьләре, әкиятләре кечкенәдән белем алырга, эш сөяргә, табигатьне сакларга өнди. Менә хәзер шул шигырьләрнең берничәсен тыңлап үтик.

1 а.б. Г.Тукайның безнең арабыздан китүенә 111 ел тула. Ләкин шагыйрьнең үлемсез шигырьләре безнең йөрәгебездә мәңгелек урын алды.Бүген карты да, яше дә Тукайны укый һәм аны олылап искә ала.

Укучылар үзләре язган шигырьләрен укыйлар.

Кичәдә катнашучылар башкаруында "Туган тел" җыры.







20 апрельдә, чираттагы «Тотальный диктант» мәгърифәтчелек акциясе узды. Әлеге чара Россия территориясендә егерменче тапкыр үткәрелә. Бу еллар эчендә тотальный диктантны миллионлаган рус телен яратучылар язган, Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбенең 50 укытучысы. акциясендә актив катнаштылар. Педагоглар диктант язалар, үзләренең орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын тикшерәләр.



Әлмәт дәүләт нефть институты 2023 нче елның 25 декабреннән 6 нчы апреленә кадәр гомуми белем бирү оешмаларының 7-11 нче сыйныф укучылары өчен төбәкара фән олимпиадалары үткәрде. Олимпиада 6 дисциплина буенча 2 турда узды. Әлеге Олимпиадада 500 гә якын укучы катнашты. Физика фәненнән финал турында Г. Тукай исемендәге Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы Багаувова Динә 2 нче урынга лаек булды. Укытучысы Минниярова Лилия Борисовна.



18 апрельдә районыбызда II районара яшь мөгаллимнәр слеты узды. "Заманча мәктәп – шәхес тәрбияләү тирәлеге" дип аталучы әлеге чарага Мөслим һәм Актаныш районнарының яшь укытучылары килде. Иртәнге сәгатьләрдә алар мәктәбездә булдылар, Алдынгылар хәрәкәтенең "Бир бишне!" акциясендә, "Остазларның әйтер сүзе бар" исемле эшлекле очрашуда катнаштылар. Психологик-педагогик юнәлештәге сыйныф укучылар яшь мөгаллимнәргә үзләренең чыгышларын тәкъдим иттеләр. Очрашуга ветеран-укытучыбыз Әлфия Измайлова да чакырылган иде. Яшь белгечләр Илшат Закиров җитәкләгән "Акыллы технологияләр" түгәрәге эшчәнлеге белән дә таныштылар.

# Мизгелләр....






















Тукай исән.
«Җыры» күңелләрдә,
Яшәсәк тә үзен күрмичә.
Тукай килә моңлы сазын уйнап,
Шагыйрьләргә тынгы бирмичә.
«Бәйрәм бүген дип сөенәм,
Тукай туган көн булгач».


Г. Тукай


Милләтемнең горурлыгы – Тукай туган бу айда!


Туган телем – Тукай теле


Туган авыл
Г.Тукай шигыре
Халык көе
Кушлавыч, 1886,1894
Өчиле 1890,1892,1911
Кырлай, 1892-1894
Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шунар күрә сөям җаным, тәнем белән.
Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.
Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.
Бу дөньяда, бәлки, күп-күп илләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.
"Туган авыл"


Мөслим
Башлана: 10:00
26 апрель - Габдулла Тукай туган көн
138 ел тулу уңаеннан бюст ачу тантанасына чакырабыз
Рәхим итегез!
Үткәрү урыны: Мәлләтамак авылы мәчете каршындагы мәйданда

# 6 нчы в сыйныфы укучылары яза...

**Ана мәхәббәте**

Яшәгән ди бер Аккош. Аның бәбкәсе туган. Ләкин ул ак булмаган, ә соры төстә икән.Көннәрдән бер көнне аккошлар башлыгы барлыккошларны мәйданга җыеп: “Кемнең бәбәкәләре соры төстә?Без алардан ваз кичәбез! Безнең патшалыкта соры аккошларга урын юк! Алар безнең сафлыгыбызга тап төшерә!” – дип игълан иткән. Ана аккош бәбкәсен саклап калыр өчен аккошлар патшалыгын ташлап китәргә карар кылган. Ул баласы үсеп җиткәнчегә кадәр ялгызы беркем дә таба аламаслык күлләрдә яшәгән.Менә бәбкә үсеп җитеп, зур матур аккошка әйләнгән. Аның элеке соры төсеннән бер эз дә калмаган. Ана аккош баласы белән кире патшалыкка кайткannар һәм бәхетле тормыш кичергәннәр.Менә шулай итеп ихлас ана мәхәббәте кечкенә бәбкә гомерен саклап калган. **Валеев Динар**

**Куянның койрыгы нигә кыска?**

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер куян. Аның койрыгы бик озын, матур, йомшак булган. Беркөнне куян кишер бакчасы янынннан узып бара икән. Аның бик тә кишер ашыйсы килгән.Ул йөгереп тә килгән, койма аша сикереп керим дигәндә, койрыгы белән коймага эләгеп калган. Шул вакытта каравылчы килеп җиткән. Ул куянның койрыгыннан нык итеп тоткан, ә куян ачарга теләп бик нык тыпырчынган. Шулчак куянның койрыгы өзелеп киткән, ул каравылчының кулыннан ычкынган. Куян урманга кереп качкан. Шулай итеп, куянның койрыгы кыска булып калган, ә каравылчы бүрекле булган. Шул көннән башлап,барлык куяннар да кыска койрыклы булып туа икән.
**Гыйздуллин.Фирзәр**

**Куян белән керпе**

Булган, ди, бер куян. Аның булган, ди, керпе дусты. Алар бергәләп көн саен уйнаганнар. Бер көнне куян керпене эзләп таба алмаган. Кыш җиткән. Шулай итеп куян керпе дустын югалттым дип уйлаган. Яз җиткәч, керпе йоклаган җиреннән торып чыккан. Куян аны күреп бик сөенгән. Керпе дустына аны югалтуын сөйләгән. Ә керпе, кыш көне йокларга ятуын анлаткан. Шуннан бирле куян белән керпе дуслар икән . **Әхмәтов Айгиз**

**Куян елы ничек барлыкка килгән?**

Һәр елны Кыш Бабай үзенең оча торган боланнары белән бүләк таратып йөри икән. Берзаман бу боланнарның ашыйсы килеп китә. Ул вакытта алар урман өстеннән очып барганнар, бу хәлне куяннар күреп, тиз генә куаклык артына качканнар. Карасалар, Кыш Бабай тора икән. Куяннар шатланып, аның янына йөгереп чыкканнар. Кыш Бабай бик кәефсез күренгән.Карт куян аннан ни өчен кәефсез икәнлеген сораган.- Нихәл, Кыш Бабай! Ни булды, ник монда туктарга булдың?- Әй, куянкайларым, менә бит боланнарымның ашыйсы килә башлады, ә аларга ашарга кыш көнендә каян азык табарга? Шулчак бер куян каядыр тиз генә йөгереп китте. Озак та үтми, аның мышный-мышный бер капчык сөйрәп килүен күрделәр. Калган куяннар аңа ярдәмгә ашыктылар. Ул кышка дип әзерләп куелган бер капчык кишерне боланнарга бүләк итәргә булган.Кыш Бабай боланнарын ашаткан да бу куянга һәм аның туганнарына бик зур рәхмәт әйткән. Һәм шулчак аның башына уй килгән: "Куяннарның да үз еллары булса, әйбәт булыр иде"Кыш Бабай куянга:- Куян дус, син булмасаң, бөтен бала бүләксез калыр, боланнар да ачтан үләр иде, рәхмәт! Рәхмәт йөзеннән сезнең барыгызга да бүләк: сезнең өчен Куян елы булдырабыз. Киләсе ел сезнең елыгыз булыр. **Балтаев Илдан**

**Зур куян**

Урманда яшәгән, ди, бер кечкенә, көлке куян. Аңардан бөтенесе көлә икән. Куян бер зирәк ябалак янына барган. Ябалак әйтә икән: «Мин бер тылсымлы үләнне беләм, ул сине зурайтачак, ләкин ул урманның иң караңгы җирендә үсә. Әгәр дә анда үзең генә барасың икән, сак бул, чөнки анда усал бүреләр һәм төлкеләр бар».Кечкенә куян бик шатланган, ләкин ул анда барырга курка икән. Ул курыкканын ябалакка әйткән. Ябалак әйтә икән: «Курыкма, мин дә синең белән барам».Икенче көнне алар урманның иң караңгы җиренә барганнар. Баралар икән үлән эзләп, шулвакыт һич көтмәгәндә зур бүре килеп чыккан. Куян бик курыккан, ә ябалак томшыгы белән куянны күтәргән дә алар бүре өстеннән очып узып та киткәннәр. Алар тылсымлы үләнне карт имән астыннан тапканнар. Куян аны ашаган да зур үскән. Ябалак әйтә икән: «Син хәзер зур, инде син шатмы? Куян әйтә икән: «Әйе, мине хәзер хөрмәт итәрләр. Куян белән ябалак өйләренә кайтып җиткәннәр. Хәзер Куян урман халкы алдында горур гына йөри икән. Зур булу аңа бик ошый, ди. Бу эштә ябалак дусты аңа бик булышкан. Алар шулай дус һәм тату булып бик озак һәм бәхетле яшәгәннәр, ди.

**Гобәйдуллин Камил**

**Куян баласы**

Борын-борын заманда куе урманда яшәгән, ди, булган, ди, куян баласы.Көннәрдән бер көнне куянның әнисе алма кайнатмасы ясарга уйлаган һәм куян баласын аланга коелган алма җыярга җибәргән. Куян баласы чәчәкләр иснәп барып ничек сукмакны югалтканын да сизми калган. Урманда адашып йөри торгач,нәкъ төлке каршына килеп чыккан ул. Шул вакыт куркуыннан куян баласы "Әни!" дип кычкырып җибәргән. Аның тавышына кошлар һәм хайваннар ояларыннан ни булганын карарга чыгалар. Куян баласының төлке кулына эләккәнен күреп, керпе төлкене энәләре белән кадый, тиеннәр чикләвек һәм чыршы күркәләре ата, кошлар төлкене чукый һәм канатлары белән суга башлыйлар. Төлке куркуыннан качарга мәҗбүр була.Шулай җәнлекләр һәм кошлар кечкенә куянны зур бәладән коткаралар.

**Кашапов Тимур**

**Кәҗә турында экият**

Борын-борын заманда яшәгән, ди, әби белән бабай. Аларның ике балалары һәм бер кәҗәләре булган. Гаилә бик ярлы яшәгән.Еллар үтеп, аларның балалары үсеп җиткәннәр һәм үз тормышларын булдырып, чыгып киткәннәр. Әби, бабай, кәҗә өчесе яшәп калганнар. Бер көнне кәҗә ике бәти алып кайткан. Әби белән бабай аларга бик шатланмаганнар. Чөнки аларның ашатырга ризыклары булмаган. Иртә белән бабай аларны базарга алып китеп сатып кайткан. Шул көннән тагын өчесе генә яши башлаганнар. Кәҗәне алар шундый яратканнар. Югалыр дип куркып, сарайдан чыгармаганнар. Көннәрдән бер көнне кәҗә авырып киткән. Аңа, авылның мал табибын чакыртканнар. Табиб хайваннар телен аңлый торган булган. Аңа кәҗә үзенең зарларын сөйләп биргән. Кәҗәнең болынга чыгып үлән ашыйсы, бәтиләре белән очрашасы килгән. Бабай шул көнне үк кәҗә бәтиләрен кире алып кайткан. Кәҗә шул көннән башлап терелеп, матурланып киткән. Алар бергә бик матур гомер иткәннәр.

**Моратов Гадел**

«Тукай ялкыны”, апрель, 2024 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф. Корреспондентлар Нуреева Алия, Җаббарова Диана
Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр.